МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 97/о

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

«28» 05 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның «28» 05 №97/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.3.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.1. Министрлык урнашкан урын: 420111, Казан ш., Дзержинский ур., 7.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның эш көннәрендә.

«Кремль» тукталышына кадәр җәмәгать транспортында № 98 автобус белән килү; «Университет» тукталышына кадәр: 8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а номерлы автобуслар; 7, 17, 20, 21 номерлы троллейбуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.»;

1.3.4 пунктчасының 2 пунктчасындагы өченче абзацында «http://uslugi.tatar.ru/» сүзләрен «http://uslugi.tatarstan.ru/» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1 (1 өл.), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – РФ ШрК);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Федераль мөлкәттә торган су объектларында булдырылган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 246-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 25.07.2011, № 30 (1 өл.), 4594 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 29 (1 кисәк), 4344 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелешкә һәм эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирүгә кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 4 июлендәге карары (Хокук мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 6 июль, басылып чышу номеры: 0001201707060016);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (http://www.pravo.gov.ru), 2015, 13 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201504130006);

«Татарстан Республикасында шәһәр төзү эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба –98-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеше), 1453 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә), («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм

боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль мөлкәттә торган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан ясалма җир кишәрлекләрен булдыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарын билгеләү турында» 2016 елның 09 июнендәге 384 номерлы карары (алга таба – 384 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы», 24.06.2016, № 46, 1497 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт һәм эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары (алга таба – 729 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru), 2017, 17 октябрь).»;

2.5 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

уналтынчы абзацта «(кулга тапшыру турында белдереп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Объектларны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт алуга кирәкле документлар бары тик электрон формада гына, техник мөмкинлек булган очракта, тапшырыла:

әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ ШрК 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), РФ ШрК 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә, РФ ШрК 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә электрон формада тапшырылган булса;

әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка төр документлар электрон формада тапшырылган булса»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «; 729 номерлы ТР МК карары» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы» графасында «; дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә әлеге документлар белән эш итүче оешма» сүзләрен өстәргә;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда аталган документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый»;

2.12 пунктында «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән»;

2.16 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен алу турында гаризаны «Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталы» мәгълүмат системасы аша Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге бар.

Техник мөмкинлек булганда документлар электрон формада «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелергә мөмкин.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшыру мөмкинлеге тудырылмаган»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «729 номерлы ТР МК карары» сүзләрен өстәргә;

4.3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Административ процедуралар үтәлешен тикшерүдә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытлары, тәртибе үтәлүенә.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның, яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә Министрлыкның (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшерүдә тотучы урынбасары яисә Министр исеменә тапшырыла. Министр урынбасарының (Министрның) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://minstroy.tatar.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны

гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.».